ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.25, с. Куралово,
422581

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 25 нче йорт, Куралово авылы,
422581

Тел.: (84379) 33-5-36, факс: (84379) 33-5-36.

11.11.2025 № 1

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Рус Борнашы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? - Рус Борнашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» (билгеләнгән урынга илтеп җиткереп, асфальт гранулат сатып алу) дигән сорау буенча 2025 елның 11 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 81 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 45 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 44 катнашучысы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? - Рус Борнашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» (билгеләнгән урынга илтеп җиткереп, асфальт гранулат сатып алу) дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Р. Е. Тарасов